МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

20.03.2025 № 16

Казан ш.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 10 мартындагы 57 номерлы боерыгы белән расланган Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 10 мартындагы 57 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 24 апрелендәге 27 номерлы боерыгы редакциясендә) белән расланган Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык 2025 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата гамәлдә булачак.

Министр Ф.М.Хәнифов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының 2025 елның
20 мартындагы 16 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 10 мартындагы 57 номерлы боерыгы белән расланган Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.6.1 пунктында:

4 пунктчада «$1^1$ өлештә каралган очракта» сүзләрен « $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга»;

5 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

2.6.2. пунктка түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^8$ өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, проект документларына кертелә торган, проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлардан тупланган әгъзаларга нигезләнгән үзкөйләнешле оешма әгъзасы булып торган зат тарафыннан тапшырылган һәм әлеге зат тарафыннан РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектлавын оештыру буенча белгеч буларак җәлеп ителгән зат тарафыннан расланган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^8$ өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүенә раслама»;

2.6.8 пунктында:

3.1 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

6 пунктчада:

«территорияне комплекслы үстерү турындагы карар» сүзләреннән соң «яисә шундый шартнамә төзелгән» сүзләрен өстәргә;

«килешү төземичә» сүзләрен «мондый килешүне төземичә» сүзләренә алмаштырырга;

2.8.2. пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) проект документациясенең территорияне планлаштыру проектында каралган территорияне планлаштырып үстерү чиратлылыгына туры килмәве

(РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының $11^{1-1}$ өлешендә каралган очракта).»;

2.8.3 пунктның 3 пунктчасында «дәүләт җир күзәтчелеге» сүзләрен «федераль дәүләт җир контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

3.6.2 пунктында 3.1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.